Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Нарат-Елга авыл җирлеге Советы

2022 елның 24 мае №22/3

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 16 августындагы 13/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы нигезендә» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 августындагы 13/1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның «в» пунктчасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

12 пунктта «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә яки Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Нарат-Елга авыл җирлеге
башлыгы А.Р. Хәмитов